**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.12.2022 г. Казань № 3422

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында

Б о е р ы к б и р ә м:

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эш тәртибен расларга.

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары А.Д.Гариповка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

Г.Р.Накипова
(843) 231-79-15

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланды
23.12.2022 № 3422

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эш
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына (алга таба – Тәртип, Министрлык) кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү үзенчәлекләрен билгели, аларга коррупция һәм янап алу фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре (алга таба – дәүләт хезмәткәре), Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булып тормый торган вазифа биләүче хезмәткәр (алга таба – хезмәткәр), шулай ук Министрлык карамагындагы учреждение җитәкчесе (алга таба – учреждение җитәкчесе) тарафынан кылынган хезмәт вазыйфасыннан законнан тыш файдалану билгеләрен үз эченә алган бүтән гамәлләр керә.

2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

3. Министрлыкта теркәлгәннән соң мөрәҗәгатьне Министрлыкта коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы Министрлыкның кадрлар бүлеге вазыйфаи затына (алга таба – коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат) карау өчен җибәрелә.

4. Кергән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы эшчәнлек әзерләнүе, башкарылуы яки башкарылганы турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында белешмәләр булганда, бу мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн эчендә аларның компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелә.

5. Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып биш көн эчендә аны карый, андагы мәгълүматларга башлангыч анализ ясый, анализ ясаганда бу белешмәләрне дәүләт хезмәткәре, хезмәткәре, учреждение җитәкчесе белән әңгәмә үткәрә һәм алардан кирәкле аңлатмалар ала.

6. Мөрәҗәгатьтә дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) коррупциячел хокук бозулар булуын күрсәтүче белешмәләр билгеләнгән очракта, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат аңа карата тикшерү уздыра башлый (Тәртипнең әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш).

Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен тикшерү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үткәрелә. Тикшерү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) (алга таба – Министр (аның вазыйфаларын башкаручы) тикшерү тәмамланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көнлек вакыт эчендә язма доклад формасында хәбәр ителә.

Министрның (аның вазыйфаларын башкаручы затның) мөрәҗәгаттә коррупция күренешләре булуы турында бәян ителгән фактларны тикшерү нәтиҗәләре буенча расланган очракта, ул алынган көннән алып ике көн эчендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә карауга җибәрелә. Күрсәтелгән комиссиянең тәкъдимен исәпкә алып, Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) дәүләт хезмәте турындагы законнар нигезендә дәүләт хезмәткәренә җаваплылык чарасын куллану мәсьәләсен хәл итә.

Дәүләт хезмәткәре ризалыгы белән һәм аның коррупцион хокук бозу фактын тану шарты белән җәза, ышанычны югалту сәбәпле эштән азат ителүдән тыш, Министрлыкның кадрлар бүлегенең гамәлләренең факттагы шартлары күрсәтелгән коррупциячел хокук бозу кылу турындагы докладьы һәм дәүләт хезмәткәренең язма аңлатмасы нигезендә кулланылырга мөмкин (Тәртипнең әлеге пунктында каралган тикшерү үткәрмичә).

7. Мөрәҗәгатьтә хезмәткәрнең, учреждение җитәкчесенең кылган гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булуын күрсәтүче белешмәләр билгеләнгән очракта, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат хезмәткәрнең, учреждение җитәкчесенең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупциячел хокук бозулар булу-булмавына мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән хәлләрне тикшерүне башлап җибәрә.

Тикшерү Министр карары (аның вазыйфаларын башкаручы) буенча үткәрелә һәм мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә тәмамланырга тиеш. Тикшерүне үткәрү Министрлыкның кадрлар бүлегенә һәм юридик бүлегенә, кирәк булган очракта, Министрлыкның башка бүлекчәләрен җәлеп итеп, йөкләнә. Тикшерү нәтиҗәләре Министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тикшерү тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн дәвамында язма бәяләмә формасында хәбәр ителә. Тикшерү тәмамлануы көне – аны үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмәгә имза салу датасы тора.

Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, хезмәткәрнең гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) коррупция чагылышлары булу турында хәбәр ителгән фактлар расланган очракта, хезмәткәрнең язмача аңлатмаларын анализлаудан чыгып, Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан аңа карата хезмәт законнары нигезендә җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) учреждение җитәкчесенең гамәлләрендә (гамәл кылмауда) коррупция күренешләре булуы турында мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларны тикшерү нәтиҗәләре буенча расланган

очракта, аны алганнан соң ике көн эчендә бәяләмә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – комиссия) җибәрелә. Комиссия тәкъдимен исәпкә алып, Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) учреждение җитәкчесенә хезмәт законнары нигезендә җаваплылык чарасын куллану мәсьәләсе хәл итә.

8. Мөрәҗәгатьне юллаган гражданга җавап әзерләү коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

9. Мөрәҗәгатьтә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затның гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупция күренеше фактлары турында белешмәләр булган очракта, соңгысы аны карауда катнашмый һәм үз кандидатурасын кире кагуын белдерә. Мондый мөрәҗәгатьне карау һәм мөрәҗәгатьне юллаган гражданга җавап әзерләү Министрлыкның кадрлар бүлеге тарафыннан әлеге Тәртип нигезендә башкарыла.

___